ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23 гыйнвар 2025 ел № 360

Башкарма комитетның «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасын раслау турында» 2022 елның 25 октябрендәге 5772 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, шәһәр Уставы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы Карары нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасын раслау турында» 2022 елның 25 октябрендәге 5772 номерлы Карарына (Башкарма комитетның 2023 елның 31 мартындагы 2593 номерлы, 2023 елның 22 декабрендәге 12417 номерлы, 2024 елның 28 августындагы 5579 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасын тормышка ашыру буенча чараларны финанслауны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Юл хуҗалыгы (юл фондлары)» 0409 бүлекләре (бүлекчәләре) буенча каралган акчалар хисабына 1 864 285,02 мең сум күләмендә тәэмин итәргә: 2023 ел – 597 662,59 мең сум, 2024 ел – 748 212,43 мең сум, 2025 ел – 518 410,00 мең сум.»;

2) кушымтада:

- 1 бүлектә «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» юлында «2024» графасында «538 292,57» санын «748 212,43» санына алмаштырырга;

- 3 бүлектә «УЮЧның норматив техник халәтен ирешелгән дәрәҗәләрдә саклап тоту» юлында «Финанслау һәм финанслау чыганаклары 2024» баганасында «538 292,57» санын «748 212,43» санына алмаштырырга;

- 4 бүлекне яңа редакциядә бәян итәргә:

«4 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программа чараларын тормышка ашыру өчен 1 864 285,02 мең сум күләмендә муниципаль бюджет акчаларын файдалану күздә тотыла: 2023 ел – 597 662,59 мең сум, 2024 ел – 748 212,43 мең сум, 2025 ел – 518 410,00 мең сум.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ф. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов